Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 декабрь, 2023 ел № 299

Җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча бурычны түләтүне һәм исәптән чыгаруны ышанычсыз дип тану турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2, 160.1 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 26 мартындагы 255 номерлы карары белән расланган (2020 елның 23 июнендәге 271, 2022 елның 7 июлендәге 165 номерлы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычны түләмәү тәртибенә таянып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 26 мартындагы 255 номерлы карары белән расланган (җирле бюджетка керү өлешендә) 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесенең, «Идарәче компания» муниципаль унитар предприятиесенең бурычын түләтүгә һәм исәптән чыгаруга карата беркетмәне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Идарәче компания» МУПның җир кишәрлекләре өчен 109300,00 (йөз тугыз мең өч йөз) сум күләмендә аренда түләве буенча бурычын түләттерүгә өметсез дип танырга һәм гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов